Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Яңа Шигали авылы Овражная урамы гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

15 декабрь, 2024 ел № 5

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Яңа Шигали авылы Овражная урамы гражданнарының 2024 елның 15 декабрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 21 (егерме бер).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 13 (унөч).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 13 (унөч).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2025 елда Яңа Шигали авылы Овражная урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 10 000 сум күләмендә үзара салым кертүгә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Овражная ур.)» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Шигали авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Шигали авыл җирлеге башлыгы В.М. Сәлимов